ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

27 гыйнвар 2017ел | № 353

Башкарма комитетның 2014 елның 20 февралендәге 1026 нчы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 448 маддәсе, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ санлы Федераль законның 19 маддәсе, Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама корылмаларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезнамәнең 43 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 20 февралендәге 1026 нчы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә реклама корылмаларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктның 8 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

2) 6 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«6. Аукцион объекты булып лот яки лотлар тора, шул ук вакытта һәр лот түбәндәгеләр турындагы мәгълүматны үз эченә ала:

- реклама корылмасының тибы;
- реклама корылмасына карата техник таләпләр;
- реклама корылмасын урнаштыру урыны;
- реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү төзү хокукының башлангыч бәясе.»;

2) 18 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«18. Түбәндәге сәбәпләр буенча дәгъвачы аукционда катнашуга кертелми:

1) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә дәгъвачының эшчәнлеге туктатылу;

2) дәгъвачы бетерелү (үзгәртеп төзелү) процессында булу;

3) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәгъвачы банкрот дип танылган һәм (яки) аңа карата банкротлык процедурасы үткәрелү;

4) тапшырылган документлар аукцион документлары таләпләренә туры килмәү;

5) заявка дәгъвачы тарафыннан әлеге гамәлләрне башкаруга вәкаләтләнмәгән зат тарафыннан тапшырылу;

6) дәгъвачының Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына срогы чыккан бурычы булу.»;

4) 29 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«29. Теләсә кайсы кызыксынучы зат Махсуслаштырылган оешмага аукцион документлары нигезләмәләре буенча аңлатмалар бирү турында запрос җибәрү хокукына ия. Махсуслаштырылган оешма күрсәтелгән запрос кергән көннән соң ике эш көне эчендә, аукцион документлары нигезләмәләре буенча язма рәвештә яки электрон документ формасында аңлатмалар җибәрергә бурычлы.

Теләсә кайсы кызыксынучы зат өчтән артмаган запрос җибәрергә хокуклы.

Кызыксынучы затның запросы буенча, аукцион документларының нигезләмәләре буенча аңлатма җибәрелгән көннән соң бер эш көне эчендә әлеге аңлатма, запрос предметын күрсәтеп, ләкин запрос җибәргән кызыксынучы затны күрсәтмичә, махсуслаштырылган оешма тарафыннан рәсми сайтка урнаштырылырга мөмкин. Аукцион документлары нигезләмәләре буенча аңлатма аның асылын үзгәртергә тиеш түгел.»;

5) 30 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«30. Аукцион заказчысы, аукционда катнашуга заявкалар бирү тәмамлану датасына кадәр кимендә биш көн кала, аукцион документларына үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Аукцион предметын үзгәртү рөхсәт ителми. Шулай ук аукционда катнашуга заявкалар бирү срогы аукцион документларына кертелгән үзгәрешләр рәсми сайтка урнаштырылган көннән аукционда катнашуга гаризалар бирүнең тәмамлану датасына кадәрге срок 15 көннән ким булмаслык итеп озайтылырга тиеш.»;

6) 31 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«31. Аукционда катнашуга дәгъвачы аукционда катнашу өчен шәхсән яки үзенең вәкиле аша түбәндәгеләрне тапшыра:

1) аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә күрсәтелгән срок эчендә, аукцион документларында билгеләнгән форма буенча аукционда катнашуга заявка;

2) дәгъвачы тарафыннан аукцион үткәрү турындагы хәбәрдә билгеләнгән задаток күчерелүне раслау өчен, түләүче банкының үтәлү турында билгесе куелган түләү документы;

3) шәхесне раслаучы документның нотариаль расланган күчермәсе (физик зат өчен);

4) оештыру документларының һәм юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклыкның нотариаль расланган күчермәләре (юридик затлар өчен);

5) законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч язуы (заявка дәгъвачының вәкиле тарафыннан бирелгән очракта);

6) зур килешүне хуплау яки аны төзү турында карар яисә зур килешү төзү өчен шундый карар булу кирәклеге турында таләп Россия Федерациясе законнарында, юридик затның оештыру документларында билгеләнгән очракта, әлеге карарның күчермәсе;

7) хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә яки шул өземтәнең нотариаль расланган күчермәсе (юридик затлар өчен); хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан алынган өземтә яки шул өземтәнең нотариаль расланган күчермәсе (шәхси эшмәкәрләр өчен); хәбәр рәсми сайтта урнаштырылган датага кадәр алты ай эчендә алынган, тиешле дәүләт законнары нигезендә юридик затның яки физик затның шәхси эшмәкәр буларак дәүләт теркәве турында документларның тиешенчә расланган рус теленә тәрҗемәсе (чит ил затлары өчен);

8) гариза бирүченең – юридик затның бетерелүе хакында карар булмау турында, гариза бирүчене – юридик затны, шәхси эшмәкәрне банкрот дип тану һәм конкурс производствосы ачу хакында арбитраж суды карары булмау турында, Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган тәртиптә гариза бирүченең эшчәнлеге туктатылу хакында карар булмау турында декларация.»;

7) 10 бүлекнең исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«10 бүлек. Аукционны үтмәгән дип тану»;

8) 51 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«51. Һәр куелган лот буенча аукцион түбәндәге очракларда үтмәгән дип танызла:

1) аукционда катнашуга бер генә катнашучы кертелсә;

2) реклама корылмаларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукының башлангыч бәясе өч тапкыр игълан ителгәннән соң аукционда катнашучыларның берсе дә билет күтәрмәсә.»;

9) 52, 53, 54 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;

10) 55 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«55. Махсуслаштырылган оешма, аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмә имзаланган көннән соң 5 банк көне эчендә, үткәрелмәгән аукцион катнашучылары тарафыннан кертелгән задатокларны кире кайтарырга бурычлы.

Аукционда җиңүче аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәне, реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүне имзалаудан яки реклама корылмасын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү төзү хокукының тәкъдим ителгән бәясен түләүдән баш тарткан очракта, кертелгән задаток җиңүчегә кире кайтарылмый.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе башлыгы И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин